ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Өркеш авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 гыйнвар №3

Өркеш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Өркеш авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Өркеш авыл җирлеге Советының 27 номерлы карарына (Өркеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 27 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 21 номерлы, 2015 елның 25 ноябрендәге 11 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 13 номерлы, 2018 елның 31 октябрендәге 21 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 27 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 28 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 20 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Өркеш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгләмова